СОВЕТ УРАЗБАХТИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.1А, с. Уразбахтино,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422155

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРАЗБАХТЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Совет ур., 1А йорт, Уразбахты авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422155

тел.(факс): (85563) 2-86-36; e-mail: UrBah.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение | Карар

№ 1-7 | «13» апрель 2016 ел

2015 елга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Уразбахты авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында

Мамадыш муниципаль районының Уразбахты авыл җирлеге бюджетының 2015 елгы үтәлеше турындагы хисап буенча һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 264.5, 264.6 статьялары нигезендә, Мамадыш муниципаль районының Уразбахты авыл җирлеге Уставының 83, 84 статьялары нигезендә, Уразбахты авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1 статья. 2015 елгы бюджет үтәлеше турындагы хисапны 4043,5 мең сум күләмендә һәм чыгымнар буенча 4048,7 мең сум күләмендә дип, һәм түбәндәге күрсәткечләр белән расларга:

2015 елда авыл җирлеге бюджеты керемнәре буенча әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә;

2015 елда авыл җирлеге бюджеты чыгымнарын әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының функциональ структурасы бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре буенча бүлеп;

2015 елда авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы буенча әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә;

2015 елгы бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә.

Статья 2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Мамадыш муниципаль районы
Уразбахты авыл җирлеге башлыгы,
Җирлек Советы рәисе Р.Т.Кәримов

.